**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Зәй тимер юл станциясе поселогы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**30 ноябрь, 2023 ел,** **№2**
**09.00**
**Зәй тимер юл станциясе бистәсе,**
**Урман яны урамы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Зәй тимер юл станциясе поселогы торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Зәй поселогы торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, гражданнарның үзара салымы 1000 сум күләмендә кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Яңа Александровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Зәй тимер юл станциясе поселогында тирән су белән тәэмин итү насосын сатып алу һәм урнаштыру.

**Бөгелмә муниципаль районының**
**"Яңа Александровка авыл җирлеге"**
**муниципаль берәмлеге гражданы**
**җыенында рәислек итүче** **Е.Г. Гыйрфанова**